КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 28 апрель г.Казань № 584

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 30 июнь, 514 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 30 июнь, 514 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 5 август, 680 нче, 2021 ел, 31 август, 788 нче, 2021 ел, 7 сентябрь, 835 нче, 2021 ел, 25 ноябрь, 1127 нче, 2021 ел, 22 декабрь, 1266 нчы, 2022 ел, 15 март, 240 нчы, 2022 ел, 22 июль, 707 нче, 2022 ел, 16 сентябрь, 1009 нчы, 2022 ел, 13 декабрь, 1319 нчы, 2022 ел, 21 декабрь, 1389 нчы, 2023 ел, 21 февраль, 168 нче, 2023 ел, 4 июль, 786 нчы, 2023 ел, 9 август, 961 нче, 2023 ел, 5 октябрь, 1239 нчы, 2024 ел, 4 март, 119 нчы, 2024 ел, 17 апрель, 258 нче, 2024 ел, 10 май, 317 нче, 2024 ел, 5 август, 622 нче, 2024 ел, 10 октябрь, 875 нче, 2025 ел, 04 апрель, 197 нче, 2025 ел, 16 июнь, 436 нчы, 2025 ел, 30 июль, 558 нче, 2025 ел, 24 декабрь, 1140 нчы, 2026 ел, 7 апрель, 351 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган элиталы орлыкчылыкка ярдәм итүгә һәм (яисә) Федераль фәнни-техник программа кысаларында җитештерелгән авыл хуҗалыгы үсемлекләренең сортлары һәм (яисә) гибридлары орлыкларын сатып алуга Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибендә:

1 пунктның «а» пунктчасындагы беренче абзацында «агымдагы финанс елы уңышын чәчү өчен файдаланылган» сүзләрен «агымдагы финанс елы уңышына чәчү максатларында» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктта:

алтынчы абзац үз көчен югалткан дип танырга;

жиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуда катнашучыларның әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «а» һәм (яисә) «б» пунктчаларында күрсәтелгән авыл хуҗалыгы культуралары орлыклары агымдагы финанс елы уңышына  чәчелгән һәм (яисә) чәчелә торган җир кишәрлекләреннән файдалану хокуклары булуын документаль раслау;»

14 пунктта:

бишенче – жиденче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$P_{эс}$ – әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән авыл хуҗалыгы культуралары орлыклары агымдагы финанс елы уңышына  чәчелгән һәм (яисә) чәчелә торган мәйдан, гектар;

С – әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән сатып алынган авыл хуҗалыгы культуралары орлыклары бәясе (өстәлгән бәягә салымны исәпкә алмыйча), 1 тоннага сум;

N – әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән сатып алынган авыл хуҗалыгы культуралары орлыклары чәчү нормасы, 1 гектарга килограмм;»;

уникесенче абзацта «агымдагы ел уңышын чәчү өчен файдаланылган» сүзләрен төшереп калдырырга;

15  пунктның икенче абзацнда «агымдагы финанс елында» сүзләрен «агымдагы финанс елы уңышы өчен» сүзләренә  алмаштырырга;

25 пунктта:

алтынчы абзацта «агымдагы ел уңышын чәчү өчен файдаланылган» сүзләрен төшереп калдырырга;

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Авыл хуҗалыгы үсемлекләре орлыкларының сортлы һәм чәчү (утырту) сыйфаты күрсәткечләренә таләпләрне һәм күрсәтелгән күрсәткечләр турында белешмәләр булган документлар формаларын раслау турында» 2024 елның 8 маендагы  246 номерлы боерагы белән расланган форма буенча авыл хуҗалыгы үсемлекләре орлыкларын сынау беркетмәсе;»;

ундүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

56 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Еллык отчет белән бер үк вакытта, субсидия алучы «Электрон бюджет» системасында әлеге Тәртипнең 1  пунктның «а» пунктчасында  күрсәтелгән, «Россия авыл хуҗалыгы үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалы тарафыннан таныкланган авыл хуҗалыгы культуралары чәчүлекләрен сынау актларының электрон күчермәләрен тәкъдим итә.»;

әлеге карар белән расланган Бәрәңге һәм яшелчәләр җитештерүне арттыруны стимуллау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибендә:

1  пунктның «б»   пунктчасының икенче абзацында «чәчелгән (утыртылган)» сүзләрен «чәчергә (утыртырга) планлаштырылган» сүзләренә алмаштырырга;

14  пунктның  уникенче - унбишенче абзацларында «чәчелгән (утыртылган)» сүзләрен «чәчергә (утыртырга) планлаштырылган» сүзләренә алмаштырырга;

25 пунктта:

икенче абзацта «сату-алу» сүзләрен «сату (сату-алу)» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацы нигезендә субсидия алу өчен сайлап алуда катнашучылар Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Авыл хуҗалыгы үсемлекләре орлыкларының сортлы һәм чәчү (утырту) сыйфаты күрсәткечләренә таләпләрне һәм күрсәтелгән күрсәткечләр турында белешмәләр булган документлар формаларын раслау турында» 2024 елның 8 маендагы 246 номерлы боерагы белән расланган форма буенча авыл хуҗалыгы үсемлекләре орлыклары пробаларын сынау беркетмәсенең өстәмә электрон күчермәсен тапшыра.»;

56 пунктта:

өченче абзацта «июль» сүзен «октябрь» сүзенә алмаштырырга;

дүртенче абзацта ««а» – «е» пунктчаларында» сүзләрен ««а» һәм «б» пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «1 пунктның «а» һәм «б» пунктчаларында күрсәтелгән юнәлешләр буенча» сүзләрен «1 пунктның «а» пунктчасында күрсәтелгән юнәлеш буенча» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта ««в», «д» һәм «е» пунктчаларында» сүзләрен ««б» пунктчасының икенче һәм дүртенче абзацларында» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән юллама буенча - «Россия авыл хуҗалыгы үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалы тарафыннан таныкланган агымдагы финанс елының орлык чәчүлекләрен апробацияләү актлары.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин